**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2025 елның 25 феврале 365/ПИК

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге, Усад авылы территориясен планлаштыру проектын раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталларны, микрорайоннарны, башка элементларны) аерып чыгару, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләренең чикләрен, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренең чикләрен билгеләү максатларында, 2025 елның 10 февралендә үткәрелгән гавами тыңлаулар нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге, Усад авылы территориясен планлаштыру проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб—адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**